**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Келәш торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

**18.11. 2020** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, . “Сез, 2021 елга түбәндәге эшләрне, ягъни:

- Сугышта һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл төзү;
- Суэтем каланчасы территориясен төзекләндерү эшләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Келәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1000 сум күләмендә акча җыелырга ризамы? сораулары буенча 2020 елның 18 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләрен кертеп, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә, сайлау хокукына ия булган 267 җыенда катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыены катнашучылары саны – 138 кеше.

Гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, киләсе рәвештә исәпләнде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенының 138 катнашучысы тавыш бирде;

“Каршы” позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кылды:

1. 1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Келәш торак пунктында узган гражданнар җыенын булып узган дип, ә җыен нәтиҗәләрен чын дип тану.

2. . “Сез, 2021 елга түбәндәге эшләрне, ягъни:

- Сугышта һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл төзү;
- Суэтем каланчасы территориясен төзекләндерү эшләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен Бөек Ватан

сугышында катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Келәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1000 сум күләмендә акча җыелырга ризамы? сораулары буенча кабул ителгән карарны чын дип тану.

«РИЗА» «КАРШЫ

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, халыкка җиткерү максатыннан, мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) беркетергә.

4. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында**
**рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Келәш авыл җирлеге**
**башлыгы** **Ф.Х. Галимов**